Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге советы Карары

2019 нчы елның 2 нче августы 12№

Салман авыл җирлеге Советының
2018 нче елның 24 нче августындагы 17 номерлы
"Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Салман авыл җирлеге торак
пунктларында гражданнар җыенын әзерләү
һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә"
карарына үзгәрешләр кертү турында

2019 нчы елның 1 нче маендагы 87-ФЗ номерлы "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында" Федерациясе Федераль законының 1 статьясындагы 13 пунктының а, б пунктчасы, 2004 нче елның 28 нче июлендәге 45-ЗРТ номерлы "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" Татарстан Республикасы законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының "Салман авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Салман авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

Салман авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 24 нче августындагы 17 номерлы "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге торак пунктларында гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.6 пунктында:

5 абзацта "федераль әһәмияттәге," сүзләреннән соң "муниципаль округ," сүзләрен өстәргә;

1.6 пунктының 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

авылара территориядә урнашкан торак пунктта яңа төзелгән җирлек булдыру турында халык инициативасын алга сөрү максатларында, шулай ук яңа төзелгән җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия булган халык саны 300 кешедән артмаган яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;

3.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3.5 халык җыены торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы анда катнашканда хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пункт халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән « Салман авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакытта үткәрелә. Шул ук вакытта

элек гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала".

2.Әлеге карар рәсми басылып чыккан мизгелдән үз көченә керә.

3.Аның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Салман авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Совет рәисе,
Әлки муниципаль районы
Салман авыл җирлеге башлыгы: Л.Ф. Гайфуллина